Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 ноябрь 2018 ел №257

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының 2011 елның 28 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль милкенә ия булу, файдалану, идарә итү һәм муниципаль милек белән эш итү тәртибе Нигезләмәсе турындагы» №77 карарына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 35 маддәсе, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» Федераль законның 5 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 июлендәге № 155-ФЗ Федераль закон, «Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2008 елның 29 апрелендәге № 57-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының 27 маддәсе нигезендә һәм Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2017 елның 12 сентябрендәге 368 номерлы протестын караганан соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2011 елның 28 апрелендәге №77 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль милкенә ия булу, файдалану, идарә итү һәм муниципаль милек белән эш итү тәртибе Нигезләмәсе турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегенең 1.1 пунктындагы «Әлмәт муниципаль районы Советының 07.08.2009 ел, № 334 карары белән расланган «Муниципаль милектәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмә» сүзләрен «Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 29 апрелендәге №62 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 3 нче «Муниципаль милекне формалаштыру» бүлегендәге 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районының муниципаль милкен исәпкә алу» махсуслаштырылган программа продукты ярдәмендә муниципаль милек реестрында алып барыла. Муниципаль милек реестры муниципаль милектә булган исәп объектлары (биналар, корылмалар, күчемле милек, җир участоклары) турында мәгълүматны чагылдыра.

Объектларны муниципаль милек реестрына кертү район Башкарма комитеты карары буенча башкарыла:

1) Россия Федерациясе дәүләт милкен федераль милеккә, Татарстан Республикасы дәүләт милкенә һәм муниципаль милеккә бүлгәндә, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән:

- федераль милек объектларын Әлмәт муниципаль районы милкенә тапшыру,

- Татарстан Республикасы Дәүләт милке объектларын Әлмәт муниципаль районы муниципаль милкенә тапшыру;

2) Әлмәт муниципаль районы бюджеты хисабына яңа төзелгән объектларны файдалануга тапшырганда;

3) гражданлык-хокукый килешүләр нәтиҗәсендә мөлкәт сатып алганда (сату-алу килешүләре, алмашу, бүләк итү килешүләре нигезендә) яисә Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган башка килешүләр нигезендә мөлкәт сатып алганда;

4) муниципаль милекне куллану нәтиҗәсендә продукция, җиләк-җимеш һәм табыш алу юлы белән;

5) суд карары нигезендә хуҗасыз муниципаль милек дип тану;

6) гамәлдәге законнарда каралган башка нигезләр буенча.

Муниципаль милек реестры мәгълүматлары ел саен актуальләшә.».

1.3.«Муниципаль милек иясе вәкаләтләре» бүлегенең 4.5 пунктында «МУ «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» сүзләренә алмаштырырга»;

1.4. «Муниципаль милекне исәпкә алу» бүлегенең 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль милек реестрында исәп объектлары булып торалар:

- муниципаль милектә булган күчемсез милек (бина, төзелеш, корылма яки төзелеп бетмәгән төзелеш объекты, җир кишәрлеге, торак, торак булмаган бина яки җир белән бәйле башка объект, күчерү зыянсыз мөмкин булмаган торак булмаган бина, закон белән күчемсез милеккә кертелгән башка мөлкәт);

- муниципаль милектә булган күчемле милек, акцияләр, хуҗалык җәмгыятенең яки ширкәтнең устав (склад) капиталында өлеше (кертемнәр) яки күчемсез мөлкәткә кагылышлы булмаган башка мөлкәт, аның бәясе тиешле муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары карарлары белән билгеләнгән күләмнән артып китә, шулай ук Автоном һәм муниципаль

учреждениеләргә беркетелгән һәм «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге №174-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән аеручa кыйммәтле күчемле мөлкәт»;

- устав (склад) капиталы Әлмәт муниципаль районы карамагында булган муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль учреждениеләр, хуҗалык җәмгыятьләре, ширкәтләр, акцияләр, шулай ук гамәлгә куючысы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлек булган башка юридик затлар.

1.5. «Муниципаль милекне исәпкә алу» бүлегенең 5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «муниципаль милекне исәпкә алу Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милек реестрларын алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 августындагы № 424 боерыгы һәм район Советының 2006 елның 19 маендагы № 71 карары белән расланган Әлмәт муниципаль районы муниципаль казна турындагы Нигезләмә нигезендә алып барыла;

1.6. 8 бүлегендәге 8.1 пунктында «РФ Хөкүмәтенең 2002 елның 12 августындагы №585 карары белән «Аукционда дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турындагы нигезләмәне һәм махсуслаштырылган аукционда дәүләт яки муниципаль милектә булган ачык акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен сатуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» сүзләрен «Аукционда дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турындагы нигезләмәне һәм махсуслаштырылган аукционда дәүләт яки муниципаль милектә булган акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен сатуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 8 бүлек 8.1 пунктында «Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен сату буенча сәүдә оештыру яки мондый җир кишәрлекләрен арендага бирү килешүләрен төзү хокукы турында» 2002 елның 1 ноябрендәге №808 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 8 бүлек «Муниципаль милекне хосусыйлаштыру»ны 8.6 пункты белән тулыландырырга:

«Дәүләт һәм муниципаль милекне теләсә нинди физик һәм юридик затлар сатып ала алалар:

дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш;

устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр өлеше 25 проценттан артып киткән, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге №178-ФЗ Федераль законның 25 маддәсендә каралган очраклардан тыш»;

Теркәлү урыны Россия Федерациясе Икътисад министрлыгы тарафыннан расланган Дәүләт яки территория булган юридик затлар, тәэмин итүче ташламалы салым режимы салым салу һәм (яки) финанс операцияләре

үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган (офшор зоналары) (алга таба-офшор компанияләр), Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә үзләренең файдалы кулланучылары, бенефициар хуҗалары һәм контрольлек итүче затлар турында мәгълүмат ачуны һәм бирүне гамәлгә ашырмый;

«Контрольлек итүче зат» төшенчәсе «Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2008 елның 29 апрелендәге № 57-ФЗ Федераль законның 5 маддәсендә кулланылган мәгънәдә кулланыла. «Файдалы кулланучы» һәм «бенефициар хуҗасы» төшенчәләре «Террорчылыкны финанслау һәм җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (отмывания) каршы көрәш турында» 2001 елның 7 августындагы №115-ФЗ Федераль законның 3 маддәсендә күрсәтелгән мәгънәләрдә кулланыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләр үз белдеге белән төзелмәгән һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез милек объектлары милекчеләренә әлеге җир кишәрлекләрен сатып алганда кагылмый».

1.9. 10 нчы «Муниципаль милек объектларын арендалау» бүлегенең 10.1 пунктында «Әлмәт муниципаль районы Советының 07.08.2009 ел, №334 карары белән расланган «Муниципаль милектәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турында карар белән расланган Нигезләмә» сүзләрен “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 29 апрелендәге №62 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы милкендә булган муниципаль милекне арендага бирү турында нигезләмә"гә алмаштырырга.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Әлмәт хәбәрләре» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Закиров Ш.К.) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин